ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 Казан шәһәре № 5-17/тэ

Кулланучыларга «Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2020 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2018 № 5-80/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга үзгәрешләр кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, һәм 2020-2021 елларга җайга салынулы оешманың план буенча кирәкле тулай табышын тәгаенләштереп, 2020-2021 елларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар билгеләү турында» 12.12.2018 № 5-80/тэ карарының 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2018 № 5-80/тэ карарына 1 кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 5-17/тэ карары редакциясендә)

## «Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2019-2021 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салучы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләш-терүче пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5тән 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см$^2$ кадәр | югары 13,0 кг/см$^2$ | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1211,22 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1247,56 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1247,56 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1284,90 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1284,90 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1312,77 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1453,46 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1497,07 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1497,07 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1541,88 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1541,88 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап | 1575,32 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 31.12.2021 кадәр | | | | | | | |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге